Хезмәттә танылган тюркологларның тамыр нигезләрнең төзелешенә, морфологик үзенчәлекләренә, семантик билгеләренә бәйле карашлары барлана. Беренчел тамырлар иң гади, кыска һәм шул ук вакытта мөһим берәмлекләр буларак, тел феноменының үзе кебек үк бик борынгы катламны тәшкил итәләр. Аларны туплау, системалаштыру бүгенге көндә тел тарихын тикшерүнең көнүзәк мәсьәләләренең берсе булып тора.

Фәнни-тикшеренү эшенең нәзари һәм гамәли әһәмияте хезмәтнең төп нәтиҗәләрен тарихи-чагыштырма, этимологик эзләнүләрдә төрки һәм алтай телләрендә тамыр теориясен эшкәртүдә файдалану мөмкинлеге белән билгеләнә.

**Төп төшенчәләр:** төрки телләр, тарихи-чагыштырма тел белеме, тамыр, нигез, реконструкция, этимология, диахрония, синкретизм, система

## Кереш

Тамыр төшенчәсе лингвистикада борынгы һинд грамматикаларында ук кулланылышта булган. Фәнни әдәбиятта иң кечкенә мәгънәви берәмлекне атау өчен *сүз тамыры, тамыр морфема, тамыр сүз, беренчел сүз, этимологик тамыр, төп морфема, тамыр нигез, сүзнең ясагыч формасы, ясагыч нигез, беренчел нигез* һ.б атамалар кулланыла.

«Тамыр нигез» проблемасы төрки телләрдә аеруча үзенчәлекле урын алып тора, чөнки һинд-европа тел гыйлемендә тамыр һәм сүзнең мөнәсәбәте, тамыр белән нигезнең тәңгәл килү мөмкинлегенә карата «тарихи табу» куелган булган [1, 99 б.]. Компаративистикадагы бу стереотип бүген дә саклана. «Тамырлар сүзләргә кадәр булганнар һәм флектив төзелеш барлыкка килгәч, сүз булып оешып киткәннәр», дигән фикерне аеруча А. А. Потебня хуплый. Төрки телләр өлкәсендә эшләүче галимнәр исә, ике сәбәп аркасында мондый табудан азат булалар: беренчедән, синхрон яссылыкта төрки сүзләр мөстәкыйль тамырга һәм башка морфемаларга ирекле аерыла ала; икенчедән, бер иҗекле тамырлар VII гасырга караган Орхон-Енисей язмаларында ук ачык теркәлгән була. «Төрки телләрдә тамырга морфологик элементларның «ябышуы» агглютинация законнарына яраклы рәвештә барган», – дип билгели кыргыз галиме Б. М. Юнусалиев. Аның фикеренчә, «төрки телләрдә тамыр нигез ролендә бер иҗекле сүз генә була ала. Күп иҗекле сүзләрнең хәтта таркалмый торганнары да тамыр нигезгә грамматик күрсәткечләр ялгану аша, яисә ике мөстәкыйль тамырның семантик яктан укмашуы, яисә фонетик «деформациясе» нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр» [2].

Тамыр нигезләр мәсьәләсе буенча басылып чыккан күпсанлы хезмәтләр һәм китерелгән карашлар аның актуальлеге турында сөйли. Төрки тамыр төзелеше турындагы фикерләр төрле елларда О. Бетлингк (1851), Г. Вамбери (1878), В. В. Радлов (1893–1911), В. Банг (1916), Н. Ф. Катанов (1903), Г. Алпаров (1945), Г. Рамстедт (1952), Л. Н. Харитонов (1954), В. Н. Хангильдин (1954), Ж. Г. Киекбаев (1955), А. Зайончковский (1961), В. Котвич (1962), Н. А. Баскаков (1962, 1979, 1988), Н. К. Дмитриев (1962), Г. Дерфер (1964),

Б. А. Серебренников (1965), В. Асланов (1965, 1971), А. М. Щербак (1970), А. Н. Кононов (1971, 1980), Ф. А. Ганиев (1974), И. В. Кормушин (1971, 1991), Э. В. Севортян (1973), Э. Р. Тенишев (1976), В. И. Цинциус (1979), Т. М. Гарипов (1979), К. М. Мусаев (1984), А. Т. Кайдаров (1986), Е. З. Кажибеков (1986), Ж. Манкеева (1991), Н. И. Егоров (1992), Б. О. Орузбаева (1994), А. Г. Шайхулов (2000) һ.б. авторларның хезмәтләрендә чагылыш таба. Аерым алганда, галимнәр бер иҗекле фигыль тамырларның сузыкка тәмамланган [Т+С] тибы булу-булмавы турында бәхәсләшәләр. Бер төркем тюркологлар (мәсәлән, Вл. Котвич) төрки, монгол, тунгус-маньчжур телләре материалын чагыштырма анализлау нигезендә төрки һәм, киңрәк – алтай, телләрендә тамыр төрле типларда – гадидән С, ТС, СТ һәм катлаулы ТСТ, ТСТТ булырга мөмкин, ди. Калган галимнәр (Г. Вамбери, В. В. Радлов, Н. А. Баскаков, А. М. Щербак) фикеренчә, киресенчә, классик типтагы бер иҗекле Т+С+Т тамыры иң борынгы тамыр структурасы тибын тәшкил итә. Бу карашның тарафдарлары уйлавынча, бары тик ТСТ тибы гына (мәсәлән, *sal-*, *bar-*, *kel-* фигыльләре) төрки телләрдә бердәнбер беренчел тамыр була ала. Алар фикеренчә, С+Т тибындагы этимологик тамырның булуы мөмкин түгел. Н.А. Баскаков ике аваздан гына торган тамыр нигезләрнең беренчеллеге мәсьәләсе турындагы теория исбатланмаган, дип билгели [3, 100 б.]. Соңрак чыккан хезмәтләрендә автор, ТС структурасындагы тамырларның борынгы язма истәлекләрдә һәм хәзерге төрки телләрдә сан ягыннан да аз булуы аларның беренчеллегенә каршы дәлил булып тора, ди. Ул төрки телләр өчен ябык иҗекле, башлангыч (анлаут) һәм ахырдагы (ауслаут) тартык аваздан торган тамыр тибы хас булуын аларның кулланылыш ешлыгы буенча 75 % тәшкил итүен дә бер факт буларак китерә [3].

Н. А. Баскаковның фикерләре төрки телләрдә тамыр теориясе турындагы өйрәтмәгә этәргеч булып тора ала. Ул галимнәр өчен эзләнүләрдә я таяну ноктасы, я күзәтүләр нигезендә барып чыгарга тиешле соңгы чик ролен үтәргә хокуклы.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Фәнни тикшеренү материалы булып тюркологиядә һәм алтаистикада тамыр теориясе буенча алып барылган эзләнүләр, фәнни хезмәтләр, сүзлекләр хезмәт итте.

Мәкаләдә тарихи-чагыштырма тел белеменең метод-алымнары, тасвирлама метод кулланылды.

## Фикер алышу

Күп кенә төрки тамырларны ТС прототибына торгызу (реконструкцияләү) мөмкинлеген күрсәткән беренче галим В. В. Радлов була. Ул үзенең «Вводные мысли к описанию морфологии тюркских языков» (1906) хезмәтендә төрки сүзләрнең морфологик элементларының керешеп китүе турында өйрәтмә тәкъдим итә. Озын үсеш юлы үткән хәзерге телләрнең күрсәткечләре буенча, төрки сүзләрнең үсеш тарихында аларның «киңәюен» күзәтергә була. Радлов сүзләре белән әйткәндә, «...мы можем далее наблюдать при рассмотрении односложных тюркских основ, что некоторые односложные всеобще распространенные основы вовсе не следует считать корнями; напротив, они возникли из сплавления исчезнувшей основы с каким-либо основообразовательным аффиксом» [4]. Мисал буларак, *баг ~ пак* «завязка», «связка» исемнәрен *-к* аффиксы ярдәмендә Орхон-Енисей язмаларында, «Кутадгу билиг»та теркәлгән *па- ~ ба-* «завязывать» фигыленнән ясалган; *сык-* «сжимать», *сын-* «ломать, разрушать«, *сыт-* «давить» фигыльләрен борынгырак **сы* тамыр нигезеннән ясалган дип күрсәтергә була [5]. Соңрак Радловның бу фикерләренә Э. В. Севортян, А. Н. Кононов кушылалар. Ул гына да түгел, күп кенә очракларда СТ тибындагы икенче тартык аваз да шундый ук схемага эләгә. Мәсәлән, Э. В. Севортянда төрек телендәге *iy-* «согласоваться, подходить, соответствовать, быть к лицу» һәм *uz* «подходящий, приличествующий» сүзләрендәге ахырдагы *y*, *z* тартыклары сүз ясагыч күрсәткечләр булып торалар [4].

Тамырларның таркалу-таркалмавыннан чыгып, Г. Вамбери «тамыр» һәм «нигез» төшенчәләрен аерып карый. Аныңча, «нигез» атамасын куллану аның составындагы «тамыр һәм аңа ялганган ясагычларны аерып карарга мөмкинлек бирә». Тюркологиядә беренчеләрдән булып, ул шушы карашны дәлилле торган 47 нигез китерә.

Төрки тамырның диахрониядәге статусын «таркалмый торган лексема» буларак карау гипотеза гына булып тора. Күп кенә белгечләр билгеләвенчә, хәзерге төрки телләрдә ике, өч иҗекле тамыр нигезләр генә түгел, хәтта бер иҗекле тамыр нигезләр дә агглютинатив үсеш

нәтиҗәсе буларак, кайчандыр мөстәкыйль яшәгән морфологик тел элементлары тәшкил итәләр. Фонетик, морфологик, семантик закончалыклар нигезендә алар шулкадәр бербөтен булып берегеп киткәннәр, бүгенге көндә аларны таркатып булмый [4, 19 б.].

Ж. А. Манкеева терминологиясе буенча тамыр теориясенә динамикада якын килергә кирәк. Тамыр онтологик дәрәҗәдәге берәмлек, шуңа күрә ул даими рәвештә үзгәрешләр кичерергә тиеш.

С, ТС, СТ тибындагы этимологик тамырларның булуы күп кенә эзләнүләрдә бәхәс тудырмый. А. Зайончковский үзенең танылган мәкаләсендә төрки телләрдә беренчел Т+С тибындагы фигыль нигезләрнең яшәеше турындагы тезиска конкрет иллюстрацияләр таба [6, 29 б.]. Автор тарафыннан тупланган материал төрки телләрдә, аеруча язма истәлекләрдә, бер иҗекле фигыль тамыр нигезләрнең ТС тибына караган мисаллары күпсанлы булуын күрсәтә. Үзенең карашын куәтләп, ул 11 тамыр нигез китерә: *ба-* «связывающий»; *йу-* «мыть», *йи-, йе-* «есть», *ку* «охранять»; *ка-* «складывать», *ко-* «поставить»; *са-* «считать»; *сы-* «разрушать»; *сү-* «тянуть»; *ти/ те-* «говорить»; *ту-* «загружать» [6]. К. М. Мусаев билгеләп үткәнчә, А.Зайончковский этимологик тамырны чагыштырма метод ярдәмендә тергезү методикасын эшкәртә [4]. Шул ук вакытта автор барлык фигыль-нигезләрне дә ТС тибына кайтарып бетереп булмый, ди.

А. Н. Кононов фикеренчә, төрки тамырның иң кыска формасы 2 тип белән билгеләнә: С, ТС һәм СТ. Киң таралыш тапкан ТСТ төренә килгәндә, «күп очракларда морфологик анализ өченче элемент (соңгы тартык) фигыльләрдә юнәлеш күрсәткече һәм исемнәрдә сүзьясагыч аффикс була», дип яза. Чынлап та, күп кенә төрки телләрдә, шул исәптән татар, башкорт телләрендә дә, ТСТ тибындагы тамыр сүзләрдә этимологик тамыр һәм юнәлеш мәгънәсен белдергән аффикс аерылган фигыльләр аз түгел. Мисал өчен *кил < *kel (кел), кит < *ket (кет)* кебек мисалларда **ke* тамыры һәм юнәлеш аффиксы аерыла [4, 20 б.].

Төрки телнең иң борынгы диалекты өчен Б. М. Юнусалиев бер иҗекле тамырларның түбәндәге 4 тибын билгели: 1) С: *у* «сон», *о-* «думать», 2) ТС: *са-* «считать», *жү* «грузить», *сы-* «ломать», *бе+н* «я», *би+з* «мы»; 3) СТ: *ат* «конь»; *ал-* «брать», *ас-* «повесить», *аң* «зверь»; 4) ТСТ: *кел-* «приходить», *ке+т* «уходить», *суғ* «вода», *тағ* «гора». Автор ТСТ тибының шартлы булуын билгели, чөнки *җак-, җан-, җал-* кебек хәзерге телләргә караган сүзләр «безнең тарихи грамматика буенча танып белү чикләребез киңәйгән саен» алга таба тагын да таркала алалар» [2].

Хәзерге төрки телләр борынгы тамыр структурасын бүгенге көндә саклап калганнар. Борынгы төрки язма истәлекләрдәге һәм хәзерге төрки телләрдәге тамыр структурасы, нигездә, бер үк типларга кайтып кала. Бу төрки телләрдә тамыр төзелешенең мең елларга сузылган консервациясе, димәк, пратөрки тамырның хәзерге телләрдә структурасы саклануы хакында сөйли [4]. К. М. Мусаевның тамыр турындагы тагын бер фикере яңалык булып тора. Ул тарихи тамырларның теге яки бу сүз төркеменә кертергә мөмкинлек бирә торган күрсәткечләре булмавын ассызыклый.

«Тамыр» төшенчәсе хәзерге төрки телләргә карата тулы, объектив, катгый билгеләмәсен тапмаган әле. Күп кенә тикшеренүчеләр фикеренчә, аның аеруча үзенчәлекле мөһим ягы – тарихи үзгәрүчәнлеге һәм аерым формантларының саклануы яки югалуы. Бу билгеләр А. Н. Кононовның түбәндәге билгеләмәсендә чагылыш таба: «Корень слова – понятие историческое в том смысле, что структура корня изменяется в зависимости от ряда обстоятельств и, в первую очередь, от сохранения или угасания словотворческой способности отдельных формантов» [4]. Мәсәлән, хәзерге төрки телләрдә *bajla-* «связывать» фигыленең ясалышы өчен *baj* «связка, узел» исеме нигез булса, ул үз чиратында, *ba-* «связывать» + *-j /ү-* фигыль ясаучы аффикстан тора; *ögrän-* «учиться» < *ög* “разум” < *ö* «думать»; *sana-* «считать» < *san* «счет» < *sa* «считать» (*san-* «считаться»).

А. Т. Кайдаров фикеренчә, «Төрки тамыр – телнең агглютинатив үсеш нәтиҗәсендәге фоно-морфо-семантик үзгәрешләренә карамастан, үзенең асылын саклап калган иң борынгы, тарихи реаль берәмлек. Ул структур яктан бер иҗектән артмаса, беренчел сүз белән тәңгәл килә. Калган очракларда тамыр телнең ясалма берәмлеге була, анда тамыр статиканы, ә сүз динамиканы күрсәтә» [7, 24 б.].

Г. Х. Алпаров, мәсәлән, «Өч иҗекле тамыр сүзләр бездә юк диярлек, аз. Булганнары да, ныклап тикшереп караганда, я ике сүздән кыскартылган, я ниндидер бер кушымча ялгап ясалган булып чыгалар» дигән фикерен белдерә [8, 58 б.]. В. Н. Хангильдин да «Татар теле

грамматикасы» хезмәтендә түбәндәгечә яза: «Тамыр сүзнең иң төп өлешен – тагын да мәгънәле кисәкләргә бүленә алмый торган кисәген тәшкил итә. Тамыр нигез тарихи яктан тагын да борынгырак, фонетик төзелеш ягыннан чагыштырмача кечерәк күләмдә була. Тамыр нигезнең күпчелеге бер яки ике иҗектән тора» [9, 28 б.].

Димәк, төрки телләрдә беренчел (этимологик, тарихи) тамырларга нигезләнеп ясалган күпсанлы икенчел тамырлар табыла.

Күпчелек галимнәр төрле төрки телләргә караган тамырларның төзелешен тикшергәндә, тамыр лексикасының бер иҗекле булуын билгелиләр. А. Т. Кайдаров төрки моносиллабларның структурасы һәм структур типлары, беренчел һәм икенчел тамырлар, эчке үзгәрешләр / фономорфологик факторлар, бер иҗекле / күп иҗекле, таркалу / таркалмау, мөстәкыйльлек/ иреклелек, тотрыклылык/ тотрыксызлык, семантик үзгәрүчәнлек/ үзгәрмәүчәнлек кебек аспектларын аерып карый. Ул «төрки телләрдә бер иҗекле тамыр нигезләр фикция түгел, ә реаль факт», – дигән фикерне куәтли һәм түбәндәге нәтиҗәләрне ясый:

1. *Тамыр → нигез → сүз* лексик берәмлекләрнең фоно-морфо-семантик структурасында эзлекле рәвештә барган агглютинатив үсеш нәтиҗәсе буларак, эчке яктан дифференциацияләнә торган чиктәш буыннннар (сылтамалар) тәшкил итәләр;

2. Тарихи тамырлар үзләренең төзелеше буенча күпчелек очракта бер иҗекле булалар: бүгенге көндә очраган бер иҗекле тамырлар арасында иң борынгы һәм беренчел типлар С (сузык), ТС (тартык + сузык) булган, ә СТ, ТСТ, СТТ, ТСТТ типлары – алга таба барган агглютинатив үсеш нәтиҗәсе;

3. Төрки бер иҗекле тамыр нигезләр ясалма тел берәмлекләре эчендә генә түгел, ә гомумән, кайчандыр телдә яшәгән ваграк морфемаларга таркала алалар;

4. Төрки бер иҗекле тамырлар хәзерге телләрдә үзаллы һәм «консервацияләнгән, этимологик караңгы, үле» формалар буларак ясалма нигезләр эченнән аерып алынырга мөмкин;

5. Төрки бер иҗекле тамыр нигезләргә гомумтөрки һәм аерым тел вәкилләрендә фономорфологик закончалыкларга яраклы рәвештә структур үзгәрүчәнлек һәм вариативлык хас;

6. Төрки бер иҗекле тамыр нигезләргә семантик яктан эчке һәм тышкы факторларга бәйле булган даими үзгәреш, үсеш хас. Бер төркем тамырларның үзаллы лексик мәгънәсе юк, аларның беренчел, гомум этимологик мәгънәсе генә билгеләнә, һәм ул мәгънә сүз төзелешенең үсешенә яраклы һәрвакыт эчке дифференциация, конкретлаштыруга дучар ителеп торган [7, 35 б.].

А. Т. Кайдаров аерым төрки телләрдәге моносиллабларның тулы корпусын булдыру һәм аны фәнни яктан тирәнтен тикшерү гомум төрки тамыр теориясен эшкәртү өчен нигез булып торуын билгели. Автор, үзе эшкәрткән теориянең принципларына таянып, казах телендәге бер иҗекле тамыр нигезләрнең сүзлеген төзи. Сүзлек мәкаләсенең башында бер иҗекле тамыр нигезләр тора, алар казах алфавиты буенча китереләләр; рус теленә тәрҗемәләр гадиләштереп, гомумиләштереп бирелгән. Гомоген тамырның барлык ясалмалары бер ояда, >, < тамгалары аша күрсәтелә. Бер семантик ояга омоним-тамырлар берләштерелә [7, 35 б.]. Мисал өчен, казах теленең бер иҗекле тамыр нигезләр сүзлегеннән өзек китерик:

*кай [qaj] I (вопрос: какой?, когда и др.): *кайда* < *кай+да* где, кайсы < кай+сы который который, какой…

*кай- [qaj-] II (синкретик: поворачивать, повернуть назад, откинуться назад, выгнуться // обратный, противоположный; зад, задняя часть, задний, западный): *кайкы* < *кай+кы* вогнутый, откинутый назад; *кайыр-* < *кай+ыр-* отворачивать, поворачивать; возвращать обратно; *кайт-* < *кай+т-* возвращаться уходить, приходить обратно; отходить. Чаг.: борынгы уйг.: обратиться назад, идти обратно, возвращаться; чув.: *кай* зад, задний, запад.

*кай [qaj] III (нечто застывшее, затвердевшее, затянувшееся пленкой, коркой): *каймак* < *кай+мак* сметана.

*кай- [qaj-] IV: *кайна* < *кай+на* кипеть; күчерелмә м. бурлить, бушевать;

*кай- [qaj-] V (синкретик покрывать, обгулять, покрытая/ огулявшая самка животных: *кайы* < *кай+ы* быть покрытой самцом. Обгуляться (о верблюдице);

*кай [qaj] VI (нечто скользкое, скользящее, плавающее по поверхности воды, по воздуху): *кайык* < *кай+ык* лодка. Чаг. кырг. телендә *кайы* скользить по воздуху; по поверхности воды (о плоском предмете) һ.б.

*кай [qaj] VII: *кайрак* < *кай+рак* точильный брусок, точило;

*кай [qaj] VIII (родственное отношение по женской линии): *кайын* < *кай+ын* родня жены; чаг.: *кат* < *кат+ын*; борынгы төрки *qad* близкий, кровный родственник (МК).

*кай [qaj] IX (нечто связанное с резанием, обрубанием, кромсанием, разрезанием): *кайшы* < *кай+шы* ножницы... Чаг. *кый* > *кыйкала-, кыр-* > *кыршы...*

*кайт- [qajt-] возвращаться, вернуться обратно. Чаг.: *кай II > кай+ыр > кай+тар- [6, 235-236 б.].

Сүзлек барлык төрки телләрнең лексик байлыгын системалаштыру өчен һәм этимологик эзләнүләр өчен база булып тора.

И. В. Кормушин «*Qa* тамырының алтай телләрендә лексик-семантик үсеше» дип аталган мәкаләсендә **qa* тамыры буенча төрки телләрдән һәм монгол, тунгус-маньчжур телләреннән чагыштырма яссылыкта тикшергән өстәмә материаллар китерә. Авторның бу хезмәтендә бүгенге көн күзлегеннән караганда таркалмый торган төрки сүзләрдәге тамыр нигезнең тарихи яктан формаль һәм семантик үсеше нәтиҗәсендә үсеше турындагы фикерләре дәлилләнә.

Мәхмүд Кашгарый тарафыннан **qa* фигыле ягма кабиләсе сөйләшендә теркәлгән, чигиләрнең җирле сөйләшендә шул ук мәгънәдә *qala* формасы кулланылуы билгеләнә [10, 13 б.]. Бу фигыльнең иң борынгы мәгънәсе якут һәм ногай телләредә сакланган: якут *xala* «салу, нәрсәгәдер берәр нәрсәне кертеп кую, йөкләү», ногай *кала* 1) «кушу, салу», 2) «тергезү, төзү». *-la-* элементы *qala* фигылендә аффикс дип санарга була; Һинд-Европа телләрен тикшерүче фәндә мондый элементларга карата «детерминатив» дигән термин кулланыла.

*Qa* тамырының борынгы истәлекләрдә һәм хәзерге төрки телләрдә киң чагылган *qat* фигыле белән чагыштырсак, *-t* элементының киңәю рәвеше мәгънәсен алганын ачыклыйбыз. *Qat* фигыленең семантикасы алга таба үсеш ала; ул «ике нәрсәне бергә кушу, җыю» мәгънәсен генә түгел, ә төрек телендәге кебек «кушу, өстәү» (нәрсәнедер нигез итеп алып, аңа өстәү, кушу), «бутау» (төрле әйберләрне кушу, гадәттә, измә турында) мәгънәләрен ала. Башкорт, якут, казах телләрендә *кату* фигыле үзенең мәгънәсен түбәндәгеләрдә махсуслаштырган: «бөтерү, әйләндерү, эрләү (җепне)», ягъни җепләрне бергә кушу һәм башкаларны билгеле бер рәвештә бербөтенгә китерү. Күрсәтелгән мәгънәдән башка башкорт һәм ногай телләрендә семантиканың конкретлашуы түбәндәге мәгънәне китереп чыгарган: «заправлять, делать приправу пище»: *Ашка корот катыу* (ашка корт салу). Шулай ук төрек телендә *katik* «ипигә тәмләткеч», татар телендә аш тәмләткечен аңлата.

Каралган сүзләр оясына *qar* фигыле кертелергә тиеш. Мәхмүт Кашгарый *qar* һәм *qat* фигыльләренең синонимлыгын – мәгънәви тиңдәшлеген билгели. Югарыда китерелгән *qat, qar* фигыльләренең мәгънәләрендәге аерма төрле төрки телләрдә бары тик башлангыч, беренчел мәгънәнең махсуслашуы белән аңлатыла ала. Ул фигыльнең лексик эчтәлегенә яңа төсмерләр кушылуда – хәрәкәт эшләү үзенчәлекләренә һәм хәрәкәтнең объектлары үзенчәлекләренә ниндидер өстәмә күрсәтмәләрдә күренә [10, 16 б.].

*Qa-, qala-, qat-* һәм *qar* фигыльләренең бер тамырга килүен, ә *-la, -t* һәм *-r* элементларын семантик аерымлану нәтиҗәсендә тамыр белән кушылган формативлар дип исәпләргә була, дип билгели И. В. Кормушин.

*Qal, qat, qar, qap* базалары белән берләшкән төрки сүзләр ачык рәвештә тышкы белдерүче ягы һәм категориаль, лексик эчтәлекләренең мөстәкыйль булуларына карамастан, аларның семантикасы уртак булуларын ачыклыйбыз. Күрсәтелгән берәмлекләрнең күплекне, җыюны күрсәтүе бу сүзләрдәге *qa* тамыр элементының уртак булуы белән бәйле. Димәк, тамырдагы икенче тартык авазлар аффикслар яки формативлар булалар. **Qa* тамырына килгәндә, модификацияләрнең бертөрлелеге анык. Ул билгеле бер «семантик ингредиентның» кабатлануында – кушу-өстәү-бутау мәгънәсе, нәрсәгә дә булса юнәлү, хәрәкәттәге кушылу, берләшү һәм бу предметларның бердәм күплеген билгеләүдә ачыла [10, 29 б.].

Э. З. Кажибеков, бер иҗекле тамырлар турындагы теорияне алга таба үстереп, төрки телләрдәге тамыр нигезләр гомогенлыгының төп чыганагы булып, мәгънәләрнең синкретик, каузатив характеры, борынгы сүзләр семантикасының комплекслы булуын күрсәтә. Борынгы сүзләр телнең күпгасырлык эволюциясеннән соң гына үзләренең лексик-грамматик мәгънәләрен конкретлаштыралар һәм морфологик яктан мөстәкыйль сүз төркемнәре булып формалашалар. Ләкин «иң элек аларның чикләре бик ачык итеп билгеләнми» [11, 44 б.].

Төрки телләрдә сүзнең морфологик үсеше телдә булган лексемаларның мәгънәләрен

беркетә. Сүз төркемнәре синкретизмы мәсьәләсен чишү формалар һәм мәгънәләр эволюциясе барышын күзәтергә мөмкинлек бирә.

Тамыр нигезләрнең барлык вариантлары да кинәт килеп чыкмаган, алар гомумтөрки үзәк лексикасы үсешенең закончалыклы, һәрбер төрки телнең фонологик структурасына һәм тарихи формалашкан артикуляцион базаның йөртүчеләренә ярашкан күренеш булып тора. Аларның, беренче карашка, буталчык булып күренгән ясалышы чынында авазларның бер-бер артлы күчешен, тирбәлешен һәм рефлектор чагылышларын тәшкил итәләр [7, 69 б.].

Төрки телләрдә [й] тартык авазы чиратлашуы нәтиҗәсендә ясалган тамыр нигез вариантлары киң таралган. Борынгы заманнан алып гомум чыганаклы, ләкин охшаш булмаган фонетик структуралы мондый лексик берәмлекләр төрле семантик эчтәлеккә ия булырга мөмкиннәр. Әлеге фикер татар теленең этимологик сүзлеге авторы Р.Г. Әхмәтьянов һәм башкорт галиме Э.Ф. Ишбердин хезмәтләрендә дә билгеләнә. Генетик яктан уртак булган *йат- ~ йад- ~ йаз- ~ йаз- ~ йар- ~ йас- ~ йал- ~ йай-* фигыль тамырлары хәзерге төрки телләрдә киң семантик кырга ия: «лежать» – «распространять(ся)» – «расширять(ся)» – «расправлять» – «растекаться» – «расстилаться» – «расширять(ся)» – «устанавливать» – «строить» – «создавать» – «рассекать» – «расколоть»... Тамырдагы авазларның борынгылыгын аның борынгы төрки язма истәлекләрендә үк чагылышы күрсәтә: *йат-* «лежать, класть, расстилать» – *йад-* «разносить, распространять, раскладывать, разливать» – *йаз-* «распространять, раскладывать, расстилать», *йаз-* «развязывать, распускать, распускаться, растекаться» – *йар-* «рассекать, расщеплять» – *йас-* «распускать, рассеивать, устанавливать, спускать» – *йал-* «вспыхивать, воспламеняться» – *йай-* «рассеивать, колебать, трясти, полоскать». Татар телендә бу фонетик чиратлашу үзенчәлекле чагылыш тапкан: *йат-* «лежать» – *йаз-* «расправлять, выпрямлять» – *йар-* «расколоть, расщеплять» – *йәй- (җәй-)* «раскинуть, расстилать, растекаться». *Йал-* тамыры ясалма нигезләрдә очрый: *йал-кын* «пламя, *йал-пак* «плоский, сплющенный», *йал-кау* «ленивый» < *йат-как* «любящий лежать»; *йас-а* «сооружать, делать, устраивать» [12]. Димәк, сүзнең фонетик структурасының үзгәреше анын семантик эчтәлеге белән тыгыз бәйләнгән, шуңа күрә татар теленең фонетикасындагы мөһим тарихи процессларны тикшерү тарихи лексикология предметына туры мөнәсәбәттә тора.

Гомоген сүзнең мәгънәләре бер үк күренешнең төрле якларын (эшнең исемен, урынын, нәтиҗәсен, коралын, предметын һәм эш / процессның башка атрибутларын) билгелиләр. Шушы фикергә яраклы кайбер мисалларга тукталыйк.

Татар телендә *аң* сүзе берничә мәгънәгә ия: 1. Кешегә хас буларак, чынбарлыкны фикерләп кабул итү, уйлый белү сәләте. 2. Кеше миендә чынбарлыкның, кешенең барлык психик эшчәнлегенең чагылыш процессы. 3. Аек караш, акыл; белем, аң-белем. *Аң-* сүзе фигыль тамыры булганда түбәндәге семантиканы белдерә: 1. Нәрсәне дә булса төшенү, эчтәлеген, мәгънәсен ачыклау. 2. Бәяләү, тану. 3. Уйлау, күз алдына китерү, күзаллау [13].

**aŋ-* «думать», «размышлять»; «помнить», «припоминать», «понимать» ↔ **aŋ* «ум», «сознание», «разум»; «восприимчивость», «понятливость», «мысль» һ.б. гомоген тамыр борынгы һәм хәзерге төрки телләрдә очрый [5, 46 б.].

Хакас **oŋna-*, төньяк-алтай **oŋno-*, һәм шулай ук **onga-* «знать», «понимать» төрки **aŋla-* белән беррәттән «*а:ң ~ аң ~ ан* һәм *ой* «мысль», «ум» арасында туры бәйләнешне ачыкларга ярдәм итә. Шуның турында ук *ойан-*га параллель булган *оңдан-* «очнуться», «проснуться», «пробудиться», «опомниться» формасы сөйли». Шулай ук бу бәйләнеш башка телләрдә дә күренә: кыргыз **ojγor-* «предполагать, умозаключать», хакас **oŋar-* «понимать, разуметь», казах, каракалпак **aŋγar-* «понимать, догадываться». **es, *uq* гомоген тамырларындагы кебек үк, **aŋla-* дериватының мәгънәләре арасында «понимать» һәм «слушать» мәгънәләрен дә аерып чыгарырга мөмкин [11, 48 б.].

ТСТ тибына караган мисалларга күзәтү ясасак, **küj* ↔ **kün II* тамырларының синкретизмын күрергә була. Борынгы төрки телләрдә **köj- ~ *kön- ~ *küj-* «гореть», «сжечь» фигыль формалары мәгълүм [5, 312, 314, 325, 646 б.]. Борынгы **kön-*, мәсәлән, төрк. **kön-ük-* «становиться загоревшим» фигылендә барлыкка килгән [11, 60 б.]. **küj-* «жечь», «припекать», «гореть» белән **kün-* охшашлыгы шул ук тәңгәллекләрне үз эченә алган, икенчел нигезләр ярдәмендә дә аңлатыла. Мәсәлән, ног. **qujas ~ *qÿjas* «солнце», «место, освещенное

солнцем»; чаг. *qujas; башк., тат. *кояш*, узб. *қуёш*, уйг. *қуяш* һәм *künäš* «солнце» [5, 327 б.]; төрек **qüneş* «солнце», чув. **χəvɛl* «солнце», төрк. **kunal* «солнце» һ.б. Татар диалектларында **kujas* «солнце» белән беррәттән шулай ук **kön* «солнце» дә мәгълүм. Шулай ук ул кушма сүзләр составында да кулланыла: *көнчыгыш, көнбатыш.*

Төрки телләрдә тамыр теориясен эшкәртүдә Уфа мәктәбе аерым бер урын алып тора. Кардәш телләр киңрәк яссылыкта – урал-алтай телләре гаиләсенә караган материалда тикшерелә.

Җ. Г. Киекбаев билгелелек-билгесезлек теориясе нигезендә сүз формаларының күрсәткечләренең тамырга бер-бер артлы ялгануы нәтиҗәсендә билгесездән билгелегә таба үсешен исбатлый. Тел баскычларының һәрберсендә – фонетикада, морфологиядә, лексикада, синтаксиста билгелелекне һәм билгесезлекне белдерүче махсус чаралар бар. Тамыр теориясе ягыннан караганда, галимнең фонетик дәрәҗәдә, ягъни авазларның билгеле бер грамматик, семантик мөмкинлекләре булуы турындагы фикерләре кызыклы. Башкача әйтсәк, сүзләр гадидән катлаулыга, билгесездән билгелегә таба агглютинация принципларына яраклы үсеш юлы үткәннәр. Мәсәлән, *лар*- күплек кушымчасы тарихи үсештә берничә этап кичергән: *-л-* > *-ла-* > *-лар.* Һәр этапта күплек мәгънәсе авазларның (фонетик берәмлекләрнең) мөмкинлекләре исәбенә тагын да ачыграк, аныграк белдерелә. Монда, мәсәлән, *-а* күрсәткеченең күплек, киңлек, билгесезлек белдерү мөмкинлеге аның акустик яктан иң киң сузык булуы белән аңлатыла. Шушы ук принцип тамырлар составында булган тартыкларны да, бигрәк тә СТ, ТСТ тибындагы тамырларда, грамматик формант буларак аерып карарга мөмкинлек бирә.

Т.М. Гарипов хезмәтләрендә Идел-Урал буе кыпчак телләренең синхрон һәм диахрон сурәтләмәсе китерелә.

Уфа мәктәбе тамыр нигезләрне тикшерүдә системалылык принципларына таяна, тел берәмлекләренең синопсисын һәм таксономиясен төзү буенча эш алып бара.

Танылган тюрколог, профессор А. Г. Шайхулов Идел-Кама-Урал этнолингвистик регионындагы телләр материалын идеографик парадигматикада тикшерә. Ул үзенең хезмәтләрендә гомумтөрки, ареаль лексикага һәм киңрәк алтай телләренең лексик берәмлекләренә дә мөрәҗәгать итә. Галим тарафыннан «Идел-Кама-Урал этнолингвистик регионының төрки, монгол, фин-угор һәм индоевропа (славян) халыкларының рухи культурасын фәнни-тикшеренү (уку) вузара лабораториясе»ндә тупланган диалекталь, хәзерге телләргә караган миллионнан артык апеллятив берәмлек теоретик күзәтүләр өчен нигез булып тора. Системалы караштан чыгып, А. Г. Шайхулов кыпчак телләренең бер иҗекле тамырларын «Табигать (җансыз, җанлы)», «Кеше» (кеше физик-биологик зат буларак», «Кеше эмоциональ, психик, хисси, аңлы зат буларак»), «Җәмгыять», «Танып белү» когнитив сфералары кысаларында тикшерә. Бер яклап, автор фикеренчә, «кардәш телләргә караган тамыр нигезләрнең синопсис рәвешендә бирелүе аларда кеше тарафыннан әйләнә-тирәне танып белү, сүздә чагылдыруның үзенчәлекле якларын ачарга мөмкинлек бирә» [4, 179 б.]. Икенче төрле әйткәндә, этимологиянең нигезендә, беренче чиратта, тамыр нигезләрне системалаштыру ятарга тиеш. Икенче яклап, А. Г. Шайхулов, бер иҗекле тамырлар турындагы танылган тюркологларның фикерләрен дәвам итеп, татар, башкорт телләрендәге бер иҗекле тамырларның фонологик комбинаторикасын, семантикасын системалы караш чикләрендә тасвирлауга ирешә.

И. С. Насипов хезмәтләрендә татар телендә фин-угор телләреннән кергән алынма сүзләр системалаштырыла [14].

Димәк, тел, безне уратып алган чынбарлыкның объектив чагылышы буларак, билгеле бер комбинатор закончалыклар, схема, модель, матрица, парадигмалар рәвешендә яши. Бүгенге көндә, күп кенә галимнәр билгеләвенчә, лингвистикада «дөньяны синергетик билгеләү» өстенлек ала. Телнең лексик-семантик системасын тикшерү дә яңа аспектларда алып барыла. Синергетика нигезендә дөньяның бердәмлеге һәм килешүчәнлеге, бөтен нәрсәнең бәйләнеше идеясе ята: «Галәмнең һәр кечкенә берәмлеге – үзенең һәм гомум яшәеш белән билгеләнгән (җанландырылган), универсумдагы барлык нәрсәләр белән бердәм яралган үзенә күрә бер дөнья» [15, 146 б.].

Дөньяның мондый бөтенлеге һәм бердәмлеге телдә беренчел тамыр нигез белән билгеләнгән этимологик оялар рәте, генетик парадигмалар аша тасвирлана. Безнең хезмәтләрдә алтай телләре гаиләсенә караган төрки, монгол,

тунгус-маньчжур телләрендә табылган уртак тамыр нигезләрнең кайбер этимологик оялары тикшерелә. Мәсәлән, борынгы төрки сүзлегендә теркәлгән этимологик *toɣ- тамыры түбәндәге семантик «буыннардан» тора: toɣ- I. 1. рождаться, возникать, появляться. 2. «восходить (о светилах) (чаг.: төрки, монгол, тунгус-маньчжур төркемнәрендә: tuɣ знамя «нечто развевающееся; поднимающееся»); toɣ- II. «подниматься, вздыматься (о пыли) »; tuɣ- II. «преграда, завал, запруда; заслонка, задвижка» → tuɣ+la- «закрывать, заделывать» [5, 584 б.]. Этимологик toɣ- < to тамыры (фонетик вариантлары tï ~ tu ~ tü ~ tö ~ tä) аерым телләрдә түбәндәге рефлекслары күзәтелә: 1) тат., башк.: *ту-, тыу-* «рождаться, возникать, появляться», чув.: *тух-* «явиться, показаться, возникнуть»; монг. *төрө-х* «рожать» < *тү-рих* «выкидывать, выбрасывать», чаг.: *тү-рс* «икра», тат., башк.: *туг-ан* «родственник; родной», *ток-ым* «поколение; порода»; калм.: *тохм* «род, происхождение», *туг-улах-* «рождать (о животных)», эвенк.: *туу-* «телиться; выводить птенцов», *ту-уэн* «двоюродный», сол.: *ту-ни* «двоюродные братья», нег.: *тув-эн* «дети женщин из рода матери; одного рода», *ту-рул* «родственник», сол.: «перерождение»; монг.: *tu-run* «внук», *торон* «родство; родня»; т. диал.: *ту-мача, то-мачей* «родные»; 2) монг. *тоос*, бур. *тоо-һон* «пыль (пыльный туман, пыль поднятая)», чаг.: *тоо-ро-г* «пыль» < *тог-ориху* «окружать, обступать со всех сторон»; ма.: *дувэ* «конец», *дуб-э* «конец, вершина, острие, верх, устье»; 3) төрки: *ток-та ~ тукта; тыгыл* «преграждаемое; накрываемое, покрываемое; противоположность, противоречие; нетронутость, совершенство, абсолют; закрытый, замкнутый, *түг-әрәк* «замкнутость, круг»; тат., башк.: *туг-ар-* «распрячь»; башк.: *ток-ан*, чув.: *тав-а* «узел, петля»; монг.: *тох-ох-* «седлать, накидывать потник», *ту-ку-* «седлать», ма.: *тох(о)-* «запрягать; обшивать невод»; борынгы төрки.: *туг-ун* «узел», монг.: *тунг* «пришивная петля на платье, пробой, скоба», *ту-на* «завязка»; уд.: *туһ-и-* «удовлетворить» [16]. Этимологик оя эчендәге лексик берәмлекләргә, уртак тамыр нигезнең үсеше белән бәйле булганга күрә, мәгънә бөтенлеге хас. Ләкин бу мәгънә бөтенлеге системалы бәйләнешләргә яраклы рәвештә әйләнә-тирә дөньяның (табигать, кеше, җәмгыятьнең) төрлелеген дә үз эченә ала.

**Нәтиҗәләр**

Сүзнең тамыры иң гади, кыска һәм шул ук вакытта мөһим берәмлек буларак, тел феноменының үзе кебек үк бик борынгы катламны тәшкил итә. Аннан башка хәзерге телләрнең генетик кардәшлеген, лексик фондның «гомоген»лыгын ачыклау мөмкин түгел. Күп гасырлар буена сузылган сүз иҗат итү дә тамырга нигезләнә.

Төрки тел белемендә тарихи тамырларның табигате турында фикерләр каршылыклы. Тамыр нигезләрнең төзелеше, структур типлары турындагы эзләнүләр ике юнәлештә алып барылган. Бер яклап караганда, тарихи тамырның, аеруча ТСТ тибының бөтенлеге билгеләнсә, икенче яклап, аның агглютинация процессларына яраклы үсеш этаплары үтүе күрсәтелә. Тамыр нигезләрнең семантик билгеләре дә мөһим аспектларның берсе булып тора. Монда тамыр нигезләрнең мәгънәсе үзгәреше, үсеше юнәлешләре, беренчел, этимологик тамыр мәгънәсенә хәзерге телдәге лексик берәмлекләрнең мәгънәсе мөнәсәбәте тикшерү предметы булып тора. Хәзерге тел белемендә тамыр нигезләрнең статусы яңа парадигмаларга яраклы системалылык, синергетика принципларына таянып тикшерелә. Димәк, тамыр сүз, этимологик тамыр, тарихи тамыр мәсьәләләре бүгенге көндә дә әле ачык булып кала бирә.

**Әдәбият**


1. *Тимирханов В. Р.* Имяславие и лингвистика корня. М.: МАКС Пресс, 2007. 248 с.
2. *Юнусалиев Б. М.* Развитие корневых слов в киргизском языке: дис. ... докт. филол. наук. М., 1953. 38 с.
3. *Баскаков Н. А.* Историко-типологическая фонология тюркских языков. М.: Наука, 1988. 207 с.
4. *Шайхулов А. Г.* Структура и идеографическая парадигматика односложных корневых основ в кыпчакских языках Урало-Поволжья в континууме ареальной, межтюркской и общетюркской лексики. Уфа, РиО БашГУ, 2000. 490 с.
5. Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 677 с.
6. *Зайончковский А. К.* К вопросу о структуре корня в тюркских языках: Глагольные основы моносиллабического (односложного) типа С+Г (согласный+гласный) // Вопросы языкознания. 1961. № 2. С. 28–35.
7. *Кайдаров А. Т.* Структура односложных корней и основ в казахском языке. Алма-Ата: Наука, 1986. 328 с.
8. *Алпаров Г. Х.* Сайланма хезмәтләр. Казан, 1945. 145 б.

9. *Хангильдин В. Н.* Татар теле грамматикасы: Морфология буенча очерклар. Казан: Таткнигоиздат, 1954. 335 б.

10. *Кормушин И. В.* Лексико-семантическое развитие корня *qa в алтайских языках // Тюркская лексикология и лексикография. М.: Наука, 1971. С.11–13.

11. *Кажибеков Е. З.* Глагольно-именная корреляция гомогенных корней в тюркских языках (явление синкретизма). Алма-Ата: Наука, 1985. 272 с.

12. *Әхмәтьянов Р. Г.* Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 174 б.

13. *Халиуллина Н. У., Шайхулов А. Г.* Тюркские языки Урало-Поволжья в контексте алтайского языкового сообщества (опыт лексико-семантического и идеографического словаря): словарь. Уфа: Восточный ун-т, 2004. Ч. I. 226 с. Ч. II. 272 с.

14. *Насипов И. С.* Опыт систематизации финно-угорских заимствований в татарском языке. Казань: ИЯЛИ, 2009. 233 с.

15. *Пятаева Н. В.* Антропоцентрический и системоцентрический принципы лингвистики в динамическом исследовании лексических гнезд. Уфа: Гилем, 2006. 280 с.

16. *Халиуллина Н. У.* Семантическая реконструкция корневых основ в этимологическом гнезде (на материале языков алтайской семьи) // Гуманитарные науки и образование. 2016. № 2 (26). С. 130–135.

**Шартлы кыскартылмалар:**

ДТС – Древнетюркский словарь

МК – Мәхмүт Кашгарыйның «Диване лөгат-эт төрк» сүзлеге

Чаг.: – чагыштыр

Тат. – татар теле

Башк. – башкорт теле

Чув. – чуваш теле

Монг. – монгол теле

Ма. – маньчжур теле

---

# АСПЕКТЫ ИЗУЧЕНИЯ КОРНЕВЫХ ОСНОВ В ТЮРКСКИХ ЯЗЫКАХ

**Нурия Усмановна Халиуллина**,
Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы,
Россия, 450000, г. Уфа, ул. Октябрьской революции, д. 3а,
nurkha@yandex.ru.

**Ильшат Сахиятуллович Насипов**,
Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы,
Россия, 450000, г. Уфа, ул. Октябрьской революции, д. 3а,
nasipov2021@yandex.ru.

В данной статье дается обзор различных направлений в тюркском языкознании, связанных с исследованием корневых основ.

В работе исследуются взгляды известных тюркологов о структуре корневых основ, морфологических особенностях, семантических признаках. Первичные корни, как наиболее простые, наименьшие и в то же время важные единицы, составляют очень древний слой, как и сам языковой феномен. Их сбор, систематизация сегодня является одной из актуальных задач исследования истории языка.

Теоретическая и практическая значимость научно-исследовательской работы определяется возможностью использования основных результатов в сравнительно-исторических, этимологических исследованиях, при разработке теории корня тюркских и алтайских языков.

**Ключевые слова:** тюркские языки, сравнительно-историческое языкознание, корень, основа, реконструкция, этимология, диахрония, синкретизм, система